Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кибәч авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кибәч авыл җирлеге Башлыгы

КАРАРЫ

2 октябрь, 2024 ел № 2

Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кибәч авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 141 номерлы Кибәч авыл җирлеге Советы карары (2021 елның 14 декабрендәге 32 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән) нигезендә карар бирәм:

1. Кибәч авылы җирлегендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

Гражданнар җыенын ике этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2024 елның 16 октябрендә 9 сәгать 00 минутта Кооператив урамы, 1А й. адресы буенча урнашкан кибет бинасы янында. Җыенда катнашучылар исемлегенә Куйбышев, Кооператив, Пролетарий урамнары буенча теркәлгән халыкны кертергә;

- гражданнар җыенының беренче этабы 2024 елның 16 октябрендә 10 сәгать 00 минутта Кооператив урамы, 5А й. адресы буенча урнашкан кибет бинасы янында. Җыенда катнашучылар исемлегенә Бохар, Гагарин, Киров, Пионер, Үзәк урамнары буенча теркәлгән халыкны кертергә;

«Сез, 2025 елда Кибәч торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларын, көндезге уку формасы студентларын, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Кибәч авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Питрәч муниципаль районы
Кибәч авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Рәимов